| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 19.12.2025 | г.Казань | № 669-2/г-2025 |

2026 елга Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга махсус өстәмә хак күләмен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгый һәм башка оешмаларны газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газ транспортлау тарифларына махсус өстәмә бәяләр билгеләү тәртибе турында» 2001 елның 3 маендагы 335 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газ транспортлау тарифларына махсус өстәмә бәяләр күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2011 елның 21 июнендәге 154-э/4 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2025 ел, №35-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга барлык кулланучы төркемнәре (халыктан тыш) өчен әлеге карар кушымтасына туры китереп, 2026 елга календарь буенча бүленгән махсус өстәмә хак күләмен билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2025 № 669-2/г-2025
карарына кушымта

2026 елга Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга календарь буенча бүленгән махсус өстәмә хак күләме

| Җайга салу чоры | Газ куллану күләме булган кулланучылар төркемнәре буенча газ бүлү челтәрләре буенча газны транспортлау хезмәтләре күрсәтү тарифына махсус өстәмә (1000 куб.м өчен сум) (елга млн.куб.м) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1000 артык | 500 башлап 1000 кадәр | 100 башлап 500 кадәр | 10 башлап 100 кадәр | 1 башлап 10 кадәр | 0,1 башлап 1,0 кадәр | 0,01 башлап 0,1 кадәр | 0,01 кадәр |
| 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 251,62 | 251,62 | 275,51 | 348,78 | 409,25 | 409,91 | 533,94 | 537,59 |
| 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 364,22 | 364,22 | 399,88 | 506,23 | 594,00 | 594,96 | 774,98 | 780,27 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге